**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет ур., 13

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район, п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**18 октябрь 2024 ел** **№ 108**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең «Каменка» шифаханәсе поселогы, Новый Поселок поселогы, Киндери тимер юл разъезды поселогы торак пунктларындагы территорияләрнең бер өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 нчы статьяларына, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 нче статьясына, Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Уставының 24 нче статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең «Каменка» шифаханәсе поселогы торак пункты территориясенең бер өлешендә - Дорожная урамында, «Каменка» шифаханәсе поселогы, Дорожная урамы, 4 нче номерлы йорт янындагы адрес буенча 2024 елның 2 ноябрендә 9 сәгать 00 минутта гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең «Каменка» шифаханәсе поселогы торак пункты территориясенең бер өлешендә - Дорожная урамында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, МХО катнашучылар һәм аларның бергә яшәүче гаилә әгъзаларыннан тыш, 2025 елда 3000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, түбәндәге эшләр:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Дорожная урамындагы поселок эчендәге юлга вак таш җәю) башкару белән килешәсезме

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Новый Поселок поселогы торак пункты территориясенең бер өлешендә - Березовая, 1-5 йортлар, Лесная, Сосновая урамнары, Новый Поселок поселогы, Лесная урамы, водокачка янындагы адрес буенча 2024 елның 2 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Новый Поселок поселогы торак пункты территориясенең бер өлешендә - Березовая, 1-5 йортлар, Лесная, Сосновая урамнары яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, МХО катнашучылар һәм аларның бергә яшәүче гаилә әгъзаларыннан тыш, 2025 елда 3000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, түбәндәге эшләр:

- коеларны төзелеш, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү башкару белән килешәсезме

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

5. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Киндери тимер юл разъезды поселогы торак пункты территориясенең бер өлешендә - Станционная урамы, 1, 2, 3А, 13, 14А, 18 йортлардан тыш, Киндери тимер юл разъезды поселогы Станционная урамы, 2А номерлы йорт янындагы адрес буенча 2024 елның 2 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Киндери тимер юл разъезды поселогы торак пункты территориясенең бер өлешендә - Станционная урамы, 1, 2, 3А, 13, 14А, 18 йортлардан тыш яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, МХО катнашучылар һәм аларның бергә яшәүче гаилә әгъзаларыннан тыш, 2025 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, түбәндәге эшләр:

- урам яктырту эшләрен башкару белән килешәсезме

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

7. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Хисаметдинов